РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

Буа шәһәре

23 июнь 2020 ел № 6-54

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибен (1 нче кушымта).

2. Буа муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль контроль төрләре исемлеген расларга һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өчен җаваплы кешеләрне билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары И.Ф. Еремеев

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Советының 2020 елның 23 июнендәге
6-54 номерлы карарына
1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль контроль төрләре исемлеген төзегәндә һәм алып барганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала (алга таба-Исемлек).

1.2. Исемлекне төзү һәм алып бару түбәндәге принциплар нигезендә башкарыла:

Исемлеккә кертелергә тиешле муниципаль контроль төрләре турындагы белешмәләргә таләпләр бердәмлеге;

Исемлектәге белешмәләрнең дөреслеген һәм үз вакытында актуальләштерелүен;

Исемлектә булган мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы.

1.3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары турында белешмәләр исемлегенә кертү өчен нигез булып муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен билгели торган яисә аны гамәлгә ашыру тәртибен һәм (яисә) шартларын үзгәртә торган норматив хокукый актлар тора.

1.4. Исемлек Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

## II. Исемлекнең структурасы, аны формалаштыру һәм алып бару тәртибе

2.1. Исемлеккә түбәндәге белешмәләр кертелә:

1) Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра торган муниципаль контроль төре исеме;

2) муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары исеме, аларның урнашкан урыны, телефоны;

3) муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органы вәкаләтләрен билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль норматив хокукый акт исеме һәм реквизитлары.

2.2. Исемлек алып бару, андагы белешмәләрнең актуаль торышын тәэмин итү, «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында (алга таба - «Идарә» ДАС) хисаплар урнаштыру, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына докладлар җибәрү, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге (алга таба - Вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.3. Исемлектәге белешмәләрнең актуаль торышын тәэмин итү максатларында Вәкаләтле орган муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруны билгеләүче (үзгәртүче) норматив-хокукый акт проектын килештерүгә юнәлдерелгән вакыттан алып бер эш көне эчендә Исемлеккә тиешле үзгәрешләр кертә.

2.4. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән исәпкә алу объектлары турында белешмәләр үзгәргәндә, аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм җирле үзидарә органнары Исемлеген (алга таба - Тәртип) алып бару тәртибе, Вәкаләтле орган, тиешле белешмәләр үзгәргән көннән алып, өч эш көне эчендә, тәкъдим ителә торган үзгәрешләрнең хокукый нигезләрен күрсәтеп, Исемлеккә үзгәрешләр кертә.

2.5. Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән норматив-хокукый акт законлы көченә кергәннән соң, Вәкаләтле орган Буа муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматны яклау бүлегенә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен урнаштыру өчен яңартылган исемлек (https://buinsk.tatarstan.ru/) җибәрә.

2.6. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру каралган Федераль законның (башка норматив хокукый актның) үз көчләрен югалткан дип танылган очракта, муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру каралган федераль законның (башка норматив хокукый актның) үз көчләрен югалткан дип танылган көннән соң өч эш көне эчендә бу хакта Вәкаләтле орган язма рәвештә хәбәр итә.